МИНИСТЕРСТВО
ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** Казан шәһәре **БОЕРЫК**

19.12.2017 №310-ОД

Татарстан Республикасы Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында нәтиҗәле кадрлар резервын формалаштыру өчен кандидатларны сыйфатлы сайлау максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында кушымтада бирелгән нигезләмәне расларга.

2. Министрлыкның «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) буенча конкурс уздыру турында нигезләмә раслау хакында» 2016 елның 8 ноябрендәге 292-ОД номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

3. Юридик бүлеккә (Л.М.Хәбибуллина) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

4. Эш башкару һәм контроль бүлегенә (Р.А.Хәбибуллина) әлеге боерыкны Министрлыкның структур бүлекчәләре җитәкчеләренә җиткерергә.

5. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.Ш.Хөсәеновка йөклим.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр А.Ә.Кәримов

Татарстан Республикасы
Сәнәгать һәм сәүдә
министрлыгының 2017
елның 19 декабрендәге
310-ОД номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Бу Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру буенча конкурс комиссиясенең (алга таба – конкурс комиссиясе) эшләү вакытлары һәм тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру методикасы билгеләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс (алга таба – конкурс) Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт хезмәтенә карата тигез дәрәҗәдә үтеп керә алуы буенча конституциячел хокукларын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукын тәэмин итә.

1.2. Министрлыкта конкурс «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 22 статьясы (алга таба – Федераль закон), Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмә раслау турында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре» 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы указы нигезендә үткәрелә.

Конкурс дәүләт граждан хезмәте (алга таба – граждан хезмәте) вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүчеләрнең профессиональ дәрәҗәсен, аларның вакантлы граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә

җавап бирүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс Федераль закон нигезендә конкурс нигезендә биләнергә мөмкин булган граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы булганда Премьер-министр урынбасары, сәнәгать һәм сәүдә министрының (аның вазыйфаларын башкаручы затның) (алга таба – министр) карары белән игълан ителә.

1.4. Министрлыкның кадрлар резервына кертүгә конкурс кадрлар бүлеге тарафыннан, Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү буенча белгечләргә мөмкин булган ихтыяҗын һәм Министрлыктагы кадрлар резервын ел саен бәяләү нәтиҗәләре буенча оештырыла.

Министрлыкның кадрлар резервына кертелүгә конкурс Министрлыкның конкурс комиссиясе тарафыннан әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә үткәрелә.

1.5. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

билгеле бер чорга биләнә торган «җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфасы вәкаләтләрен биләү өчен билгеләнгәндә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә һәм азат ителә торган, «җитәкчеләр» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә;

ашыгыч хезмәт контракты төзелгәндә;

Федераль законның 28 статьясының 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм 60.1 статьясының 9 өлешендә каралган очракларда граждан хезмәткәрен дәүләт граждан хезмәтенең бүтән вазыйфасына билгеләгәндә;

граждан хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәрен (гражданинны) граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

1.6. Алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрне файдалануга бәйле булган, Министрлык боерыгы белән раслана торган вазыйфалар исемлеге буенча аерым граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә Министрлыкта вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс үткәрелмәскә мөмкин.

1.7. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

сәләтләре һәм һөнәри әзерлеге нигезендә граждан хезмәтенә тигез дәрәҗәдә үтеп керүдә Россия Федерациясе гражданнарының  конституциячел хокукларын, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукларын тәэмин итү;

граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча аеруча туры килә торган кандидатларны федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатларның гомуми саны арасыннан сайлап алу;

граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Министрлыкның кадрлар резервын формалаштыру.

1.8. Конкурслар үткәргәндә хәл ителә торган бурычлар:

барлык кандидатлар өчен дә алар тарафыннан конкурс биремнәре һәм процедуралары үтәлгәндә тигез шартларны тәэмин итү;

кандидатларны объектив һөнәри әһәмияткә ия критерийлар нигезендә бәяләү;

конкурс процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезләнгән күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән, конкурста катнашучы затлар арасында граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларына (кадрлар резервына кертүгә) карата таләпләргә туры килә торган затларны билгеләү.

## II. КОНКУРС КОМИССИЯСЕ ТӨЗҮ ҺӘМ АНЫҢ ЭШЛӘҮ ТӘРТИБЕ

2.1. Министрлыкта конкурслар уздыру өчен министр боерыгы нигезендә Министрлыкның даими нигездә эшләүче конкурс комиссиясе төзелә. Конкурс комиссиясенең составы Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссия составына кертелгән вазыйфаи затларның шәхси составы үзгәртелгәндә, министр боерыгы белән тиешле үзгәрешләр кертелә.

2.2. Конкурс комиссиясе Рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.3. Комиссия рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмый торганда, аның хокукларын һәм вазыйфаларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясенең сәркатибе конкурс комиссиясенең эшен тәэмин итә (гаризаларны кабул итү, эшләрне формалаштыру, конкурс комиссиясе утырышлары карарларын рәсмиләштерү һ.б.).

2.4. Конкурс комиссиясе составына министр һәм (яки) ул вәкаләт биргән граждан хезмәткәрләре (шул исәптән Министрлыкның кадрлар, юридик бүлегеннән һәм Министрлыкның граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрелә торган структур бүлекчәсеннән), Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук министр гарызнамәсе буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан бәйсез экспертлар – граждан хезмәтенә бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр сыйфатында экспертларның шәхси мәгълүматларын күрсәтмичә чакыртыла торган фәнни, белем бирү һәм башка оешмаларның вәкилләре керә. Бәйсез экспертлар саны конкурс комиссиясендәге әгъзаларның гомуми саныннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет әгъзаларының һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясендәге барлык әгъзалар санының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

2.5. Алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздырылганда конкурс комиссиясе составы Россия Федерациясенең дәүләт сере турында законнары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

2.6. Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул

ителә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеге калмаслык итеп төзелә.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми исәбендәге кимендә өчтән ике өлеше катнашса, ул тулы хокуклы булып санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалар катнашында гына уздыру рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе карары кандидат юклыгында кабул ителә.

2.9. Конкурс уздыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү нигезендә аның утырышта катнашкан әгъзалары тавышларының гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәл иткеч була.

2.10. Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кабул ителә торган карарлар (комиссиядә тавыш бирү нәтиҗәләре) конкурс комиссиясе беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, анда рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм конкурс комиссиясе утырышында катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары кул куя.

2.11. Конкурсны оештыру һәм конкурс үткәрүне, конкурс комиссиясе эшен тәэмин итүне турыдан-туры оештыруны Министрлыкның кадрлар бүлеге гамәлгә ашыра.

## III. КОНКУРСТА КАТНАШУЧЫЛАР

3.1. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) буенча кандидатларга карата таләпләргә җавап бирә торган һәм шушы Нигезләмәнең 3.7 пункты белән күздә тотылган чорда әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган гражданнар конкурста катнашуга кертелә.

3.2. Граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфасына (саклап тотыла торган хезмәткәрләр исәбендәге граждан хезмәте вазыйфасына) карата квалификация таләпләренә туры килмәве, шулай ук Федераль законда билгеләнгән чикләүләренә бәйле рәвештә гражданин (граждан хезмәткәре) конкурста катнашуга кертелми.

3.3. Федераль законның 57 статьясының 1 өлешендәге 2 яисә 3 пунктында яки 59.1 статьясының 2 яисә 3 пунктында каралган дисциплинар йөкләмәсе булган дәүләт хезмәткәре Министрлыкның кадрлар резервына кертелә алмый.

3.4. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен кандидатларга карата таләпләр дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнде.

3.5. Россия Федерациясенең конкурста катнашырга теләк белдергән гражданины Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

шәхси гариза (әлеге Нигезләмәгә кушымта);

Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган үрнәк буенча тутырылган һәм имзаланган сораунамә, фото белән;

паспорт яки аны алмаштыра торган документ (тиешле документ конкурска

килгәч шәхсән күрсәтелә) күчермәсе;

кирәкле һөнәри белем, квалификацияне һәм эш елларын раслый торган документлар:

хезмәт кенәгәсе күчермәсе (хезмәт эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш), яисә гражданинның хезмәт эшчәнлеген раслый торган башка документлар һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган белешмәләр;

белеме турында һәм квалификациясе турында документларның күчермәләре, шулай ук, ихтыяры буенча, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификациясен күтәрүне яки бирелүне раслый торган документларның, фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирелү турында документларның нотариаль яктан яки эшчәнлек башкару (хезмәт үтү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе;

гражданинда граждан хезмәтенә керүгә яки аны үтүгә комачаулый торган чирләрнең булмавы турында документ (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2009 елның 14 декабрендәге 984н номерлы боерыгы белән расланган 001-ГС/у исәпкә алу формасы);

Федераль законда, башка федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган бүтән документлар.

3.6. Конкурста катнашу теләген белдергән, Министрлыкта граждан хезмәте вазыйфасын биләүче граждан хезмәткәре гаризаны министр исеменә тапшыра.

Башка дәүләт органында вазыйфа биләүче, конкурста катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәре Министрлыкка министр исеменә шәхси гариза һәм үзе тутырган, имзалаган һәм үзе граждан хезмәтен били торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган формадагы анкетаны фотосын теркәп тапшыра.

3.7. Гражданинның (граждан хезмәткәренең) ризалыгы белән аңа дәүләт серен яки закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга рөхсәт бирү процедурасы рәсмиләштерелә, әгәр дә гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан биләү өчен дәгъва белдерелгән граждан хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү мондый белешмәләрдән файдалануга бәйле булса.

Гражданин тарафыннан Министрлыкка бирелгән белешмәләрнең дөреслеге тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә тапшырылган белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылган рәвештә тикшерелә.

Граждан хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген тикшерү ул граждан хезмәте вазыйфаларының югары төркеменә караган граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурста катнашкан очракта гына гамәлгә ашырыла.

3.8. Әлеге Нигезләмәнең 3.4 һәм 3.5 пунктларында күрсәтелгән документлар аларны кабул итү турында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында игълан урнаштырылган көннән башлап 21 календарь көн эчендә Министрлыкка

гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан шәхсән, почта аша җибәреп яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә күрсәтелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон рәвештә җибәрелә.

Документларны игътибарга лаек сәбәпсез вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданиннан (граждан хезмәткәреннән) аларны кабул итеп алудан баш тарту өчен нигез булып тора.

Хөрмәткә лаек сәбәп аркасында документларны үз вакытында тапшырмаганда, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда министр аларны кабул итү вакытын күчерергә хокуклы.

## IV. КОНКУРС УЗДЫРУ МЕТОДИКАСЫ

4.1. Конкурсны үткәргәндә кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларына таянган, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган конкурс биремнәре һәм процедуралары кулланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү билгеләре Министрлыкта граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләнгән квалификация таләпләренә туры китереп эшләнгән.

Конкурс үткәрелә торган вазыйфаларның төркеменә һәм категориясенә карап, конкурста катнашучыларны бәяләү критерияләре һәм сайланган алымнар үзгәртелергә мөмкин.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу аларның конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын үтү нәтиҗәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.4. Конкурс ике этапта үткәрелә.

4.4.1. Беренче этапта Министрлыкның кадрлар бүлеге түбәндәгеләрне оештыра:

конкурсны уздыру турындагы мәгълүматны әзерли һәм Министрлыкның рәсми сайтларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыра, аңа түбәндәгеләр керә: граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасының (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасының) исеме, әлеге вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре, граждан хезмәтен узу шартлары, кандидатлар тарафыннан Министрлыкка дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлеге нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, күрсәтелгән документларны кабул итү тәмамланырга тиешле чор, конкурсны уздыру датасы, аны үткәрү урыны һәм тәртибе, башка материаллар. Конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында игълан һәм конкурс турында мәгълүмат шулай ук вакытлы басма матбугатта да бастырылырга мөмкин;

гражданин (граждан хезмәткәре) тапшырган документларны тикшерә; гражданинның (граждан хезмәткәренең) квалификация таләпләренә туры килүен тикшерә (һөнәри белем дәрәҗәсе, граждан хезмәте (башка граждан хезмәтенең)

чоры яки белгечлеге буенча эшләү чоры (тәҗрибәсе), әзерлек юнәлеше, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәре һәм күнекмәләре).

4.4.2. Тикшерү барышында гражданинның Федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә граждан хезмәтенә керүенә комачау итүче шартлар ачыкланган очракта, аңа конкурста катнаштырудан кире кагуның сәбәпләре турында министр тарафыннан язмача рәвештә хәбәр ителә. Әгәр гражданин конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган булса, конкурста катнаштырудан кире кагу сәбәпләре хакында хәбәрләмә аңа дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

4.4.3. Конкурста катнашуга кертелмәгән, вакантлы вазыйфаны биләп торуга дәгъва белдерүче зат әлеге карарга Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

4.4.4. Министрлыкта граждан хезмәтенең бер вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) карата куелган квалификация таләпләренә җавап бирә торган кимендә ике кандидатның булуы конкурсның беренче этабын төгәлләү шарты булып тора, бу хәл кандидатларны алга таба сайлау мөмкинлеген тәэмин итә.

Кандидатлар булмаса яки вазыйфага квалификация таләпләренә туры килә торган бер генә кандидат булса, конкурс узмаган дип танылa. Бу очракта бердәнбер кандидатка таләп ителүче кандидатлар саны булмауга бәйле рәвештә конкурсның узмаган дип танылуы хакында язмача хәбәр ителә.

4.4.5. Конкурсның беренче этабы тәмамлангач министр конкурсның икенче этабын уздыру датасы (катнашу өчен документлар кабул итү тәмамланганнан соң 30 календарь көне узганчы), вакыты һәм урыны турында карар кабул итә. Дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга рөхсәт рәсмиләштерелгән очракта, конкурсның икенче этабын уздыру чорын министр билгели.

Кадрлар бүлеге, конкурсның икенче этабы башланырга кимендә 15 календарь көн кала, Министрлыкның рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында аның уздырылу датасы, урыны һәм вакыты хакында мәгълүмат урнаштыра һәм кандидатларга тиешле хәбәрләрне язмача рәвештә юллый, бу вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрә.

4.4.6. Конкурсның икенче этабында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатлары бәяләнә;

Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурста җиңүчене билгеләү турында конкурс комиссиясе карары кабул ителә.

4.4.7. Конкурс уздырылганда конкурс комиссиясе кандидатларны алар

тарафыннан тапшырылган белеме, граждан хезмәтен яки бүтән дәүләт граждан хезмәтен үтүе, башка хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруы турындагы документлар нигезендә, шулай ук тест уздыру һәм кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын бәяләү буенча Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган методларны файдаланып, бүтән конкурс процедуралары нигезендә, шул исәптән тест уздыру, структур бүлекчә эшчәнлеге юнәлеше буенча кандидатлар Министрлыкта аны биләү өчен дәгъва белдергән граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасы) буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле мәсьәләләрдә шәхси әңгәмә уздыру юлы белән бәяли.

4.4.8. Министрлыкта дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына керүгә) дәгъва белдергән кандидатларга тест уздыру Татарстан Республикасы Президенты каршында Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты раслый торган Тест уздыру методикасына туры китереп гамәлгә ашырыла.

4.4.9. Тест үткән кандидатлар белән шәхси әңгәмәләр конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан үткәрелә.

Шәхси әңгәмә кандидатларның булачак һөнәри хезмәт итү эшчәнлеге темасы буенча конкурс комиссиясе әгъзаларының сораударына бирелә торган җавапларыннан гыйбарәт, әңгәмә барышында конкурс комиссиясе кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын граждан хезмәте вазыйфасына һәм әлеге вазыйфа буенча вазыйфаи регламентның бүтән нигезләмәләренә карата тиешле квалификация таләпләреннән чыгып, шулай ук әлеге Нигезләмәгә һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турындагы законнарында билгеләнгән башка нигезләмәләргә таянып бәяли.

4.5. Конкурс комиссиясенең конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә кертелгән карары конкурсның икенче этап нәтиҗәсе һәм бер үк вакытта конкурсның йомгаклау нәтиҗәсе булып тора.

4.6. Кандидатлар тарафыннан тупланган тавышлар саны, кандидатлар тарафыннан дәгъва белдерелүче вазыйфа караган структур бүлекчә җитәкчесе фикере Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен кандидат турында карар кабул итү һәм конкурска йомгак ясау өчен нигез булып тора.

4.7. Конкурс уздыру нәтиҗәсендә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасын) биләү өчен барлык кирәкле таләпләргә җавап бирә торган кандидатлар ачыкланган очракта, министр өстәмә конкурс сынауларын үткәрү турында карар кабул итәргә яки кабат конкурс уздыру турында тәкъдим кертә ала.

4.8. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен конкурс нәтиҗәләре нигезендә конкурста җиңүчене граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү турында министр боерыгы чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә. Конкурс комиссиясе шулай ук тәкъдим холкына ия булган, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен конкурста җиңмәгән, ләкин профессиональ һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында карар кабул итәргә хокуклы.

Кандидатның ризалыгы белән, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы караган шул ук төркемдәге граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен, аны кадрлар резервына кертү турында министр боерыгы чыгарыла.

Граждан хезмәткәрен (гражданинны) – конкурста җиңүчене кадрлар резервына кертү министр боерыгы белән рәсмиләштерелә.

4.9. Конкурс нәтиҗәләре хакында хәбәрләр ул тәмамланганнан соң 7 көнлек чорда кандидатларга язмача рәвештә, бу вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә. Шушы ук чорда конкурс нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында һәм «Интернет» челтәренең күрсәтелгән мәгълүмат системасында да урнаштырыла.

4.10. Кандидат конкурс комиссиясе карарын Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять кылырга хокуклы.

4.11. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дәгъва белдергән, ләкин конкурста катнашуга кертелмәгән кандидатларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары язма гаризалары буенча конкурс тәмамланган көннән соң өч ел дәвамында аларга кайтарып бирелергә мөмкин. Әлеге чор тәмамланганчыга кадәр документлар Министрлык архивында саклана, аннан соң юкка чыгарылырга тиеш. Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә тапшырылган документлар өч ел дәвамында саклана, шуннан соң бетерелергә тиеш.

4.12. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрелгән урынга бару һәм кайту, торак бинага түләү, яшәү, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һәм башкасы) кандидатлар тарафыннан үз акчалары хисабыннан түләнә.

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәгә кушымта

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрына

___________________________________

кемнән ____________________________

(фамилия, исем, ата исеме)

яши торган адрес:____________________

___________________________________

тел. ________________________________

e-mail _______________________________

ГАРИЗА

Сездән мине Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) буенча конкурска кертүегез турында үтенәм

____________________________________________________________________________

(вазыйфа атамасы)

____________________________________________________________________________

(структур бүлекчә атамасы)

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы указы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турында башка норматив хокукый актлар, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә белән, шул исәптән әлеге вазыйфаны биләү буенча билгеләнә торган квалификация таләпләре белән дә, таныштым.

Дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга карата рөхсәт алуны рәсмиләштерү процедурасы үткәрелүенә риза.

Конкурс уздыру датасы һәм урыны турында e-mail яки күрсәтелгән кесә телефоны номерына СМС-хәбәр җибәрү ярдәмендә хәбәр алуга риза.

Гаризага терким: (теркәлә торган документларны санап чыгарга).

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

__________ _______________________________________ __________

(имза) (тулы имза) (дата)